**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об утверждении Порядка организации и проведения опросов населения об эффективности деятельности руководителей органов местного самоуправления городских округов и муниципальных районов Республики Татарстан, унитарных предприятий и учреждений, действующих на республиканском и муниципальном уровнях, акционерных обществ, контрольный пакет акций которых находится в собственности Республики Татарстан или в муниципальной собственности, осуществляющих оказание услуг населению городских округов и муниципальных районов Республики Татарстан, с применением информационно-телекоммуникационных сетей и информационных технологий

В целях реализации Указа Президента Российской Федерации от 28 апреля 2008 года № 607 «Об оценке эффективности деятельности органов местного самоуправления городских округов и муниципальных районов», постановления Правительства Российской Федерации от 17 декабря 2012 года № 1317 «О мерах по реализации Указа Президента Российской Федерации от 28 апреля 2008 г. № 607 «Об оценке эффективности деятельности органов местного самоуправления городских округов и муниципальных районов» и подпункта «и» пункта 2 Указа Президента Российской Федерации от 7 мая 2012 г. № 601 «Об основных направлениях совершенствования системы государственного управления» **постановляю**:

1. Утвердить Порядок организации и проведения опросов населения об эффективности деятельности руководителей органов местного самоуправления городских округов и муниципальных районов Республики Татарстан, унитарных предприятий и учреждений, действующих на республиканском и муниципальном уровнях, акционерных обществ, контрольный пакет акций которых находится в собственности Республики Татарстан или в муниципальной собственности, осуществляющих оказание услуг населению городских округов и муниципальных районов Республики Татарстан, с применением информационно-телекоммуникационных сетей и информационных технологий (далее – опросы населения) согласно приложению № 1.

2. Образовать экспертную комиссию по рассмотрению и анализу результатов оценки населением эффективности деятельности руководителей органов местного самоуправления городских округов и муниципальных районов Республики Татарстан, унитарных предприятий и учреждений, действующих на республиканском и муниципальном уровнях, акционерных обществ, контрольный пакет акций которых находится в собственности Республики Татарстан или в муниципальной собственности, осуществляющих оказание услуг населению городских округов и муниципальных районов Республики Татарстан (далее – экспертная комиссия), и утвердить ее состав согласно приложению № 2.

3. Министерству экономики Республики Татарстан:

до 1 февраля 2014 года утвердить форму для проведения опросов населения об эффективности деятельности руководителей органов местного самоуправления городских округов и муниципальных районов Республики Татарстан, унитарных предприятий и учреждений, действующих на республиканском и муниципальном уровнях, акционерных обществ, контрольный пакет акций которых находится в собственности Республики Татарстан или в муниципальной собственности, осуществляющих оказание услуг населению городских округов и муниципальных районов Республики Татарстан, с применением информационно-телекоммуникационных сетей и информационных технологий (далее – форма для проведения опросов населения);

до 1 марта 2014 года утвердить методику подведения итогов опросов населения;

ежегодно до 1 апреля года, следующего за отчетным, представлять на рассмотрение экспертной комиссии итоги опросов населения;

совместно с Министерством информатизации и связи Республики Татарстан ежегодно обеспечивать размещение на официальном сайте Министерства экономики Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет»:

до 1 февраля года, следующего за отчетным, – формы для проведения опросов населения;

до 1 мая года, следующего за отчетным, – итогов опросов населения.

4. Министерству информатизации и связи Республики Татарстан:

до 1 февраля 2014 года обеспечить техническую возможность проведения опросов населения в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

5. Кабинету Министров Республики Татарстан обеспечить ежегодное размещение на официальном портале Правительства Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет»:

до 1 февраля года, следующего за отчетным, – гиперссылки на интернет-ресурс, содержащий форму для проведения опросов населения;

до 1 мая года, следующего за отчетным, – гиперссылки на интернет-ресурс, содержащий итоги опросов населения.

6. Предложить главам городских округов и муниципальных районов Республики Татарстан обеспечить ежегодное размещение на официальном сайте городского округа или муниципального района соответственно в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет»:

до 1 февраля года, следующего за отчетным, – гиперссылки на интернет-ресурс, содержащий форму для проведения опросов населения;

до 1 мая года, следующего за отчетным, – гиперссылки на интернет-ресурс, содержащий итоги опросов населения.

7. Республиканскому агентству по печати и массовым коммуникациям «Татмедиа» ежегодно с 1 февраля по 1 марта года, следующего за отчетным, информировать население через республиканские средства массовой информации о проведении опросов населения.

8. Контроль за исполнением настоящего Указа возложить на Кабинет Министров Республики Татарстан.

9. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань,Кремль
29 января 2014 года
№ УП-79

Приложение № 1
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «29» января 2014 года

№ УП-79

**Порядок**
**организации и проведения опросов населения об эффективности деятельности руководителей органов местного самоуправления городских округов и муниципальных районов Республики Татарстан, унитарных предприятий и учреждений, действующих на республиканском и муниципальном уровнях, акционерных обществ, контрольный пакет акций которых находится в собственности Республики Татарстан или в муниципальной собственности, осуществляющих оказание услуг населению городских округов и муниципальных районов Республики Татарстан, с применением информационно-телекоммуникационных сетей и информационных технологий**

## I. Общие положения

1. Настоящий Порядок регламентирует деятельность по организации и проведению с применением информационно-телекоммуникационных сетей и информационных технологий опросов населения об эффективности деятельности руководителей:

органов местного самоуправления городских округов и муниципальных районов Республики Татарстан – глав и руководителей исполнительных комитетов городских округов и муниципальных районов Республики Татарстан (далее – руководители органов местного самоуправления);

унитарных предприятий и учреждений, действующих на республиканском и муниципальном уровнях, акционерных обществ, контрольный пакет акций которых находится в собственности Республики Татарстан или в муниципальной собственности, осуществляющих оказание услуг населению городских округов и муниципальных районов Республики Татарстан (далее – руководители организаций).

2. Основной целью проведения опросов населения об эффективности деятельности руководителей органов местного самоуправления и руководителей организаций с применением информационно-

телекоммуникационных сетей и информационных технологий (далее – опросы населения) является определение степени удовлетворенности населения городского округа или муниципального района деятельностью руководителей органов местного самоуправления и руководителей организаций по критериям оценки населением эффективности деятельности руководителей органов местного самоуправления и руководителей организаций, утвержденным постановлением Правительства Российской Федерации от 17 декабря 2012 года № 1317 (далее – критерии оценки населением), в установленных сферах деятельности, повышение эффективности работы руководителей органов местного самоуправления, руководителей организаций.

## II. Проведение опросов населения

3. Опросы населения проводятся с 1 февраля по 1 марта года, следующего за отчетным.

4. Опросы населения осуществляются на территории Республики Татарстан через государственную информационную систему Республики Татарстан «Официальный портал Республики Татарстан», официальные сайты городских округов и муниципальных районов Республики Татарстан (далее – официальный портал Республики Татарстан, сайты муниципальных образований) по утверждаемой Министерством экономики Республики Татарстан форме для проведения опросов населения.

5. Форма для проведения опросов населения размещается Министерством экономики Республики Татарстан совместно с Министерством информатизации и связи Республики Татарстан на официальном сайте Министерства экономики Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

На официальном портале Республики Татарстан и сайтах муниципальных образований размещаются гиперссылки на интернет-ресурс, содержащий форму для проведения опросов населения.

6. При посещении официального портала Республики Татарстан, сайтов муниципальных образований пользователям предлагается принять участие в опросах населения.

## III. Подведение итогов опросов населения

7. Подведение итогов опросов населения осуществляется Министерством экономики Республики Татарстан.

8. После заполнения пользователями формы для проведения опросов населения на официальном портале Республики Татарстан и сайтах муниципальных образований данные интегрируются для формирования сводных результатов.

9. При подведении итогов опросов населения учитывается общее число респондентов по каждому городскому округу и муниципальному району

Республики Татарстан, принявших участие в опросе населения, и высчитывается доля удовлетворенных (неудовлетворенных) из числа опрошенных по каждому критерию формы для проведения опросов населения.

10. Итоги опросов населения подводятся по критериям, указанным в форме для проведения опросов населения, в разрезе городских округов и муниципальных районов Республики Татарстан и по трем группам муниципальных образований Республики Татарстан:

I группа – городские округа и муниципальные районы, административными центрами которых являются города республиканского значения;

II группа – муниципальные районы, административными центрами которых являются города районного значения и поселки городского типа;

III группа – муниципальные районы, административными центрами которых являются сельские населенные пункты.

11. Итоги опросов населения до 1 апреля года, следующего за отчетным, представляются Министерством экономики Республики Татарстан на рассмотрение экспертной комиссии по рассмотрению и анализу результатов оценки населением эффективности деятельности руководителей органов местного самоуправления городских округов и муниципальных районов Республики Татарстан, унитарных предприятий и учреждений, действующих на республиканском и муниципальном уровнях, акционерных обществ, контрольный пакет акций которых находится в собственности Республики Татарстан или в муниципальной собственности, осуществляющих оказание услуг населению городских округов и муниципальных районов Республики Татарстан (далее – экспертная комиссия).

12. Итоги опросов населения до 1 мая года, следующего за отчетным размещаются Министерством экономики Республики Татарстан совместно с Министерством информатизации и связи Республики Татарстан на официальном сайте Министерства экономики Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

На официальном портале Республики Татарстан и сайтах муниципальных образований размещаются гиперссылки на интернет-ресурс, содержащий итоги опросов населения.

## IV. Порядок работы экспертной комиссии

13. Экспертная комиссия рассматривает итоги опросов населения до 1 мая года, следующего за отчетным.

14. При рассмотрении итогов опросов населения экспертная комиссия руководствуется значениями (в процентном соотношении) по каждому показателю в разрезе городских округов и муниципальных районов Республики Татарстан, полученными в результате опроса населения.

15. В первый год проведения опросов населения их результаты принимаются по доле удовлетворенных (неудовлетворенных) из числа опрошенных по итогам отчетного года.

Наивысшее значение (в процентном соотношении) по показателю в разрезе городских округов и муниципальных районов Республики Татарстан в каждой группе означает лучший результат, соответственно, наименьшее значение (в процентном соотношении) означает худший результат.

16. В последующие годы результаты опросов населения принимаются по динамике значений (в процентном соотношении) за отчетный год по сравнению с годом, предшествующим отчетному.

Наибольший прирост значения (в процентном соотношении) по показателю по сравнению с годом, предшествующим отчетному, в разрезе городских округов и муниципальных районов Республики Татарстан в каждой группе означает лучший результат, соответственно, наибольшее снижение значения (в процентном соотношении) означает худший результат.

17. В отношении руководителей органов местного самоуправления и руководителей организаций, имеющих значения критериев оценки населением ниже пороговых значений, утверждаемых экспертной комиссией, либо имеющих снижение значений таких критериев за отчетный год более чем на 30 процентов, экспертной комиссией может проводиться дополнительное исследование результативности управления соответственно муниципальным образованием или организацией.

При дополнительном исследовании результативности управления муниципальным образованием (дополнительном анализе развития муниципального образования и работы органов местного самоуправления) экспертная комиссия может использовать итоги мониторинга и оценки эффективности деятельности органов местного самоуправления городских округов и муниципальных районов в целях выработки рекомендаций по достижению наилучших значений показателей деятельности органов местного самоуправления.

18. При выявлении экспертной комиссией обоснованных причин низкой оценки населением эффективности деятельности руководителей по результатам опросов населения экспертная комиссия может рекомендовать:

руководителям органов местного самоуправления разработать и реализовать программу по повышению результативности деятельности органов местного самоуправления и решению выявленных в ходе анализа проблем развития с установлением целевых индикаторов на плановый период;

руководителям организаций разработать и реализовать программу по повышению результативности деятельности организаций и решению выявленных в ходе анализа проблем развития с установлением целевых индикаторов на плановый период;

органам исполнительной власти Республики Татарстан принять меры по повышению качества управления и решению выявленных проблем в различных сферах;

органам исполнительной власти Республики Татарстан и органам местного самоуправления, уполномоченным заключать трудовые договоры с руководителями организаций, расторгнуть трудовой договор с руководителем организации в установленном законодательством Российской Федерации, законодательством Республики Татарстан и муниципальными правовыми актами порядке;

Президенту Республики Татарстан, представительному органу муниципального образования направить инициативу об удалении главы муниципального образования в отставку.

19. Органы исполнительной власти Республики Татарстан могут оказывать содействие руководителям органов местного самоуправления и руководителям организаций в разработке и реализации программ повышения результативности.

При необходимости допускается совместная разработка и реализация программ повышения результативности руководителями органов местного самоуправления и руководителями организаций.

20. Экспертная комиссия образуется в составе председателя, заместителя председателя, секретаря и членов экспертной комиссии.

Состав экспертной комиссии утверждается Президентом Республики Татарстан.

21. Руководит деятельностью экспертной комиссии председатель экспертной комиссии.

В случае временного отсутствия председателя экспертной комиссии его функции выполняет заместитель председателя экспертной комиссии.

22. Заседание экспертной комиссии считается правомочным, если в нем приняло участие не менее двух третей ее состава.

23. Решение экспертной комиссии по итогам опроса населения принимается путем открытого голосования большинством голосов от общего числа присутствующих на заседании членов экспертной комиссии. При равенстве числа голосов голос председателя экспертной комиссии является решающим.

24. Решение экспертной комиссии оформляется протоколом, в котором содержатся сведения о членах экспертной комиссии, присутствовавших на заседании экспертной комиссии, результатах голосования экспертной комиссии.

Протокол экспертной комиссии ведется секретарем и подписывается председательствующим на заседании экспертной комиссии.

25. Информационно-аналитическое и организационно-техническое обеспечение деятельности экспертной комиссии осуществляется Министерством экономики Республики Татарстан.

## V. Использование итогов опросов населения

26. Итоги опросов населения в отношении деятельности руководителей органов местного самоуправления используются органами исполнительной

власти Республики Татарстан при проведении мониторинга и оценки эффективности деятельности органов местного самоуправления городских округов и муниципальных районов Республики Татарстан.

27. Итоги опросов населения в отношении деятельности руководителей организаций учитываются органами исполнительной власти Республики Татарстан и органами местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан при назначении или продлении трудовых договоров с руководителями организаций, а также в рамках осуществления полномочий собственника или акционера при подготовке и принятии решений в отношении органов управления организаций.

Приложение № 2
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «29» января 2014 года

№ УП-79

**Состав**
**экспертной комиссии по рассмотрению и анализу результатов оценки населением эффективности деятельности руководителей органов местного самоуправления городских округов и муниципальных районов Республики Татарстан, унитарных предприятий и учреждений, действующих на республиканском и муниципальном уровнях, акционерных обществ, контрольный пакет акций которых находится в собственности Республики Татарстан или в муниципальной собственности, осуществляющих оказание услуг населению городских округов и муниципальных районов Республики Татарстан**

| | |
|---|---|
| Халиков Ильдар Шафкатович | Премьер-министр Республики Татарстан, председатель экспертной комиссии |
| Сафаров Асгат Ахметович | Руководитель Аппарата Президента Республики Татарстан, заместитель председателя экспертной комиссии |
| Шарифуллин Марат Дамирович | заместитель министра экономики Республики Татарстан, секретарь экспертной комиссии |
| Беляков Роман Юрьевич | заместитель руководителя Департамента Президента Республики Татарстан по вопросам внутренней политики – начальник Управления по взаимодействию с институтами гражданского общества |
| Бикеев Игорь Измаилович | первый проректор, проректор по научной работе Института экономики, управления и права, доктор юридических наук, профессор (по согласованию) |
| Гарипов Ильнур Махмутович | заместитель Руководителя Аппарата Президента Республики Татарстан – начальник Управления по работе с территориями Президента Республики Татарстан |

| | |
|---|---|
| Гаталов Евгений Николаевич | заместитель директора Департамента развития, комплексной оценки деятельности субъектов Российской Федерации и органов местного самоуправления Министерства регионального развития Российской Федерации (по согласованию) |
| Зарипов Марат Ривгатович | председатель Государственного комитета Республики Татарстан по тарифам |
| Зарипов Равиль Хамматович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр промышленности и торговли Республики Татарстан |
| Кандилов Валерий Петрович | руководитель Территориального органа Федеральной службы государственной статистики по Республике Татарстан (по согласованию) |
| Мухарямов Наиль Мидхатович | директор Института массовых коммуникаций и социальных наук Казанского (Приволжского) федерального университета, председатель Межвузовского координационного совета по гуманитарным наукам, доктор политических наук, профессор (по согласованию) |
| Сафин Ленар Ринатович | министр транспорта и дорожного хозяйства Республики Татарстан |
| Сулейманов Рифнур Хайдарович | директор ОАО «Татэнергосбыт» (по согласованию) |
| Тузиков Андрей Римович | декан факультета промышленной политики и бизнес-администрирования, заведующий кафедрой государственного, муниципального управления и социологии Казанского национального исследовательского технологического университета, доктор социологических наук, профессор (по согласованию) |
| Файзуллин Ирек Энварович | министр строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан |
| Фардиев Ильшат Шаехович | генеральный директор ОАО «Сетевая компания» (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Фомин<br>Анатолий Алексеевич | председатель Общественной палаты Республики Татарстан (по согласованию) |
| Хазиев<br>Раузил Магсумянович | генеральный директор ОАО «Генерирующая компания» (по согласованию) |
| Хамаев<br>Азат Киямович | министр земельных и имущественных отношений Республики Татарстан |
| Шагиахметов<br>Мидхат Рафкатович | министр экономики Республики Татарстан |
| Шайхутдинов<br>Роман Александрович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр информатизации и связи Республики Татарстан |
| Шакиров<br>Минсагит Закирович | председатель Совета муниципальных образований Республики Татарстан (по согласованию) |

___________

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары халкына хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, төбәк дәрәҗәсендә һәм муниципаль дәрәҗәдә эш итүче унитар предприятиеләр һәм учреждениеләр, акцияләренең контроль пакеты Татарстан Республикасы милкендә яки муниципаль милектә булган акционер җәмгыятьләре җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге турында, мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен һәм мәгълүмат технологияләрен кулланып, халыктан сораштырулар оештыру һәм үткәрү тәртибен раслау хакында**

Россия Федерациясе Президентының «Шәһәр округларының һәм муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2008 елның 28 апрелендәге 607 номерлы Указын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Президентының «Шәһәр округларының һәм муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2008 елның 28 апрелендәге 607 номерлы Указын һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указының 2 нче пунктындагы «и» пунктчасын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2012 елның 17 декабрендәге 1317 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында **карар бирәм:**

1. 1 нче кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары халкына хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, төбәк дәрәҗәсендә һәм муниципаль дәрәҗәдә эш итүче унитар предприятиеләр һәм учреждениеләр, акцияләренең контроль пакеты Татарстан Республикасы милкендә яки муниципаль милектә булган акционер җәмгыятьләре җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге турында, мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен һәм мәгълүмат технологияләрен кулланып, халыктан сораштырулар (алга таба – халыктан сораштырулар) оештыру һәм үткәрү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары халкына хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, төбәк дәрәҗәсендә һәм муниципаль дәрәҗәдә эш итүче унитар предприятиеләр һәм учреждениеләр, акцияләренең контроль пакеты Татарстан Республикасы милкендә яки муниципаль милектә булган акционер җәмгыятьләре җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген халык бәяләве йомгакларын карап тикшерү һәм анализлау буенча эксперт комиссиясе (алга таба – эксперт комиссиясе) төзергә һәм аның составын 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына:

2014 елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары халкына хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, төбәк дәрәҗәсендә һәм муниципаль дәрәҗәдә эш итүче унитар предприятиеләр һәм учреждениеләр, акцияләренең контроль пакеты Татарстан Республикасы милкендә яки муниципаль милектә булган акционер җәмгыятьләре җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге турында, мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен һәм мәгълүмат технологияләрен кулланып, халыктан сораштырулар үткәрү формасын (алга таба – халыктан сораштырулар үткәрү формасы) расларга;

2014 елның 1 мартына кадәр халыктан сораштыруларга йомгак ясау методикасын расларга;

ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 1 апреленә кадәр, халыктан сораштырулар йомгакларын эксперт комиссиясе каравына кертергә;

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән бергәләп һәр ел саен Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәгеләрне урнаштыруны тәэмин итәргә:

хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр – халыктан сораштырулар үткәрү формаларын;

хисап елыннан соң килүче елның 1 маена кадәр – халыктан сораштырулар үткәрү йомгакларын.

4. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына:

2014 елның 1 февраленә кадәр халыктан сораштырулар үткәрү өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә техник мөмкинлек тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендәге рәсми порталында ел саен түбәндәгеләрне урнаштыруны тәэмин итәргә:

хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр – халыктан сораштырулар үткәрү формасы урнаштырылган интернет-ресурска гиперсылтаманы;

хисап елыннан соң килүче елның 1 маена кадәр – халыктан сораштыру йомгаклары урнаштырылган интернет-ресурска гиперсылтаманы.

6. Татарстан Республикасы шәһәр округлары һәм муниципаль районнары башлыкларына шәһәр округы яисә муниципаль районның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында ел саен түбәндәгеләрне урнаштыруны тәэмин итү тәкъдиме ясарга:

хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр – халыктан сораштырулар үткәрү формасы урнаштырылган интернет-ресурска гиперсылтаманы;

хисап елыннан соң килүче елның 1 маена кадәр – халыктан сораштыру йомгаклары урнаштырылган интернет-ресурска гиперсылтаманы.

7. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленнән 1 мартына кадәр, халыктан сораштырулар үткәрү турында республика массакүләм мәгълүмат чаралары аша халыкка хәбәр итәргә.

8. Әлеге Указның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

9. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2014 ел, 29 гыйнвар
№ ПУ-79

Татарстан Республикасы
Президентының
2014 елның «_29_» _гыйнварындагы
ПУ-_79_ номерлы Указына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары халкына хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, төбәк дәрәҗәсендә һәм муниципаль дәрәҗәдә эш итүче унитар предприятиеләр һәм учреждениеләр, акцияләренең контроль пакеты Татарстан Республикасы милкендә яки муниципаль милектә булган акционер җәмгыятьләре җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге турында, мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен һәм мәгълүмат технологияләрен кулланып, халыктан сораштырулар оештыру һәм үткәрү тәртибе**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Бу Тәртип мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен һәм мәгълүмат технологияләрен кулланып түбәндәгеләрнең җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге турында халыктан сораштырулар оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели:

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары - Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары башлыклары һәм җитәкчеләре (алга таба – җирле үзидарә органнары җитәкчеләре);

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары халкына хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы, төбәк дәрәҗәсендә һәм муниципаль дәрәҗәдә эш итүче унитар предприятиеләр һәм учреждениеләр, акцияләренең контроль пакеты Татарстан Республикасы милкендә яки муниципаль милектә булган акционер җәмгыятьләре (алга таба – оешмалар җитәкчеләре).

2. Җирле үзидарә органнары җитәкчеләре һәм оешмалар җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге турында, мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен һәм мәгълүмат технологияләрен кулланып, халыктан сораштырулар (алга таба – халыктан сораштырулар) уздыруның төп максаты – шәһәр округы һәм муниципаль район халкының җирле үзидарә органнары җитәкчеләре һәм оешмалар җитәкчеләре эшчәнлегеннән канәгать булуы дәрәҗәсен эшчәнлекнең билгеләнгән өлкәләрендә Россия

Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 17 декабрендәге 1317 номерлы карары белән расланган җирле үзидарә органнары җитәкчеләре һәм оешмалар җитәкчеләре эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең халык тарафыннан бәяләнүе критерийлары буенча (алга таба – халык тарафыннан бәяләнү критерийлары) билгеләү, җирле үзидарә органнары җитәкчеләре, оешмалар җитәкчеләре эшенең нәтиҗәлелеген арттыру.

## II. Халыктан сораштыру үткәрү

3. Халыктан сораштырулар хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленнән 1 мартына кадәр үткәрелә.

4. Халыктан сораштырулар Татарстан Республикасы территориясендә «Татарстан Республикасының рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының рәсми сайтлары (алга таба – Татарстан Республикасының рәсми порталы, муниципаль берәмлекләр сайтлары) аша Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан раслана торган халыктан сораштырулар үткәрү формасы буенча гамәлгә ашырыла.

5. Халыктан сораштырулар үткәрү формасы Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән бергәләп, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

Татарстан Республикасының рәсми порталында һәм муниципаль берәмлекләр сайтларында халыктан сораштырулар үткәрү формасын үз эченә алган интернет-ресурска гиперсылтама урнаштырыла.

6. Татарстан Республикасының рәсми порталына, муниципаль берәмлекләр сайтларына кергәндә файдаланучыларга халыктан сораштыруларда катнашырга тәкъдим ителә.

## III. Халыктан сораштыруларга йомгак ясау

7. Халыктан сораштыруларга йомгак ясауны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы гамәлгә ашыра.

8. Татарстан Республикасының рәсми порталында һәм муниципаль берәмлекләр сайтларында халыктан сораштырулар үткәрү формасы файдаланучылар тарафыннан тутырылганнан соң, мәгълүматлар җыелма күрсәткечләр формалаштыру өчен берләштерелә.

9. Халыктан сораштыруларга йомгак ясаганда һәр Татарстан Республикасы шәһәр округы һәм муниципаль районы буенча халыктан сораштыруларда катнашкан респондентларның гомуми саны исәпкә алына һәм халыктан сораштырулар формасының һәр критерие буенча

сораштырылучылар арасыннан канәгать булган (канәгать булмаган) гражданнар өлеше исәпләп чыгарыла.

10. Халыктан сораштыруларга Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары яссылыгында халыктан сораштырулар үткәрү формасында күрсәтелгән критерийлар һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең өч төркеме буенча йомгак ясала:

I төркем – административ үзәкләре республика әһәмиятендәге шәһәр булган шәһәр округлары һәм муниципаль районнар;

II төркем – административ үзәкләре район әһәмиятендәге шәһәр һәм шәһәр тибындагы поселоклар булган муниципаль районнар;

III төркем – административ үзәкләре авыл торак пунктлары булган муниципаль районнар.

11. Халыктан сораштырулар нәтиҗәләре хисап елыннан соң килә торган елның 1 апреленә кадәр Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары халкына хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, төбәк дәрәҗәсендә һәм муниципаль дәрәҗәдә эш итүче унитар предприятиеләр һәм учреждениеләр, акцияләренең контроль пакеты Татарстан Республикасы милкендә яки муниципаль милектә булган акционер җәмгыятьләре җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген халык бәяләве йомгакларын карап тикшерү һәм анализлау буенча эксперт комиссиясенә (алга таба – эксперт комиссиясе) кертелә.

12. Халыктан сораштырулар йомгаклары хисап елыннан соң килә торган елның 1 маена кадәр Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән бергәләп, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

Татарстан Республикасының рәсми порталында һәм муниципаль берәмлекләр сайтларында халыктан сораштырулар йомгаклары күрсәтелгән интернет-ресурска гиперсылтама урнаштырыла.

## IV. Эксперт комиссиясенең эш тәртибе

13. Эксперт комиссиясе хисап елыннан соң килүче елның 1 маена кадәр, халыктан сораштырулар йомгакларын карап тикшерә.

14. Халыктан сораштырулар йомгакларын карап тикшергәндә, эксперт комиссиясе Татарстан Республикасы шәһәр округлары һәм муниципаль районнары яссылыгында халыктан сораштырулар нәтиҗәсендә алынган һәр күрсәткеч күләменә (процент нисбәтендә) таяна.

15. Халыктан сораштырулар үткәрелгән беренче елда аның нәтиҗәләре хисап елы йомгаклары буенча сораштырылган гражданнар саныннан канәгать булганнар (канәгать булмаганнар) өлешеннән чыгып ясала.

Һәр төркемдә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре яссылыгындагы иң югары күрсәткеч (процент нисбәтендә) – иң яхшы нәтиҗәне, ә иң түбән күрсәткеч (процент нисбәтендә) иң начар нәтиҗәне белдерә.

16. Алдагы елларда халыктан сораштырулар нәтиҗәләре, үткән ел белән чагыштырып, хисап елындагы күрсәткечләр динамикасы буенча (процент нисбәтендә) кабул ителә.

Һәр төркемдә Татарстан Республикасы шәһәр округлары һәм муниципаль районнары яссылыгында үткән ел белән чагыштырылган күрсәткечнең иң нык артуы (процент нисбәтендә) – иң яхшы нәтиҗәне, күрсәткечнең иң нык кимүе (процент нисбәтендә) тиешенчә иң начар нәтиҗәне белдерә.

17. Халык тарафыннан бәяләнү критерийларының эксперт комиссиясераслый торган чик күрсәткечләреннән түбәнрәк булган йә хисап елында мондый критерий күрсәткечләре кимүе 30 проценттан артып киткән җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә һәм оешмалар җитәкчеләренә карата эксперт комиссиясе тарафыннан тиешенчә аларның муниципаль берәмлек яки оешма белән идарә итүләренең нәтиҗәлелегенә өстәмә тикшерү үткәрелергә мөмкин.

Муниципаль берәмлек белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген өстәмә тикшергәндә (муниципаль берәмлек үсешенә һәм җирле үзидарә органнары эшенә өстәмә анализ ясаганда) эксперт комиссиясе, җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең иң яхшы күрсәткечләренә ирешү буенча тәкъдимнәр эшләү максатларыннан чыгып, шәһәр округларының һәм муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге бәясен һәм мониторинг йомгакларын файдалана ала.

18. Халыктан сораштыру нәтиҗәләре буенча эксперт комиссиясе тарафыннан җитәкчеләр эшчәнлеге нәтиҗәлелеген халыкның түбән бәяләве өчен нигезле сәбәпләр булуы ачыкланса, эксперт комиссиясе түбәндәгеләрне тәкъдим итә ала:

җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү һәм, план чорына максатчан индикаторлар билгеләп, анализлау барышында ачыкланган үсеш проблемаларын хәл итү буенча программа эшләүне һәм гамәлгә ашыруны;

оешмалар җитәкчеләренә оешмалар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү һәм, план чорына максатчан индикаторлар билгеләп, анализлау барышында ачыкланган үсеш проблемаларын хәл итү буенча программа эшләүне һәм гамәлгә ашыруны;

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына идарә итүнең сыйфатын яхшырту һәм төрле өлкәләрдә ачыкланган проблемаларны хәл итү чараларын күрүне;

Татарстан Республикасының оешмалар җитәкчеләре белән хезмәт шартнамәләре төзергә вәкаләтле башкарма хакимият органнарына һәм җирле үзидарә органнарына Россия Федерациясе законнары, Татарстан

Республикасы законнары һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртипләр нигезендә оешма җитәкчесе белән хезмәт шартнамәсен өзүне;

Татарстан Республикасы Президентына, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына муниципаль берәмлек башлыгын отставкага җибәрү турында инициатива белән чыгуны.

19. Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә һәм оешмалар җитәкчеләренә нәтиҗәлелекне күтәрү программаларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда булышлык күрсәтә ала.

Кирәк булганда, җирле үзидарә органнары җитәкчеләре һәм оешмалар җитәкчеләре тарафыннан нәтиҗәлелекне күтәрү программаларын бергәләп эшләү һәм гамәлгә ашыру рөхсәт ителә.

20. Эксперт комиссиясе рәис, рәис урынбасары, секретарь һәм эксперт комиссиясе әгъзаларыннан тора.

Эксперт комиссиясе составы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

21. Эксперт комиссиясе эшчәнлегенә эксперт комиссиясе рәисе җитәкчелек итә.

Эксперт комиссиясе рәисе вакытлыча үз урынында булмаганда, аның функцияләрен эксперт комиссиясе рәисе урынбасары үти.

22. Эксперт комиссиясе утырышы, әгәр дә анда комиссия составының кимендә өчтән ике өлеше катнашса, эш йөртергә хокуклы булып санала.

23. Халыктан сораштырулар йомгаклары буенча эксперт комиссиясе карары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы эксперт комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан тавышларның күпчелеге белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булган очракта, эксперт комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч була.

24. Эксперт комиссиясе карары эксперт комиссиясе утырышында катнашкан эксперт комиссиясе әгъзалары, эксперт комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре турындагы мәгълүматларны үз эченә алган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Эксперт комиссиясе беркетмәсен секретарь алып бара, аңа эксперт комиссиясе утырышында рәислек итүче кул куя.

25. Эксперт комиссиясе эшчәнлеген мәгълүмати-аналитик һәм оештыру-техник яктан тәэмин итүне Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы башкара.

## V. Халыктан сораштырулар йомгакларыннан файдалану

26. Җирле үзидарә органнары җитәкчеләре эшчәнлегенә карата халыктан сораштырулар йомгаклары Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тарафыннан Татарстан Республикасы шәһәр округлары һәм муниципаль районнары җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең

нәтиҗәлелегенә мониторинг үткәргәндә һәм аларга бәя биргәндә файдаланыла.

27. Оешмалар җитәкчеләре эшчәнлегенә карата халыктан сораштырулар йомгаклары Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан оешмалар җитәкчеләрен билгеләгәндә яки алар белән хезмәт шартнамәләрен озайтканда, шулай ук оешмаларның идарә органнарына карата карарлар әзерләгәндә һәм кабул иткәндә милекче яки акционер вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда исәпкә алына.

Татарстан Республикасы
Президентының
2014 елның «29» гыйнварындагы
ПУ-79 номерлы Указына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары халкына хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, төбәк дәрәҗәсендә һәм муниципаль дәрәҗәдә эш итүче унитар предприятиеләр һәм учреждениеләр, акцияләренең контроль пакеты Татарстан Республикасы милкендә яки муниципаль милектә булган акционер җәмгыятьләре җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген халык бәяләве йомгакларын карап тикшерү һәм анализлау буенча эксперт комиссиясе**
**составы**

| | |
|---|---|
| Халиков<br>Илдар Шәфкать улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры, эксперт комиссиясе рәисе |
| Сәфәров<br>Әсгать Әхмәт улы | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе, эксперт комиссиясе рәисе урынбасары |
| Шәрифуллин<br>Марат Дамир улы | Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары, эксперт комиссиясе секретаре |
| Беляков<br>Роман Юрьевич | Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе урынбасары – Граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлек идарәсе башлыгы |
| Бикеев<br>Игорь Измаилович | Икътисад, идарә һәм хокук институтының беренче проректоры, фәнни эш буенча проректоры, юридик фәннәр докторы, профессор (килешү буенча) |
| Гарипов<br>Илнур Мәхмүт улы | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы |

| | |
|---|---|
| Гаталов Евгений Николаевич | Россия Федерациясе Төбәкләр үсеше министрлыгының Россия Федерациясе субъектлары һәм җирле үзидарә органнары үсеше һәм аларның эшчәнлеген комплекслы бәяләү департаменты директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Зарипов Марат Ривгать улы | Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Зарипов Равил Хаммат улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Кандилов Валерий Петрович | Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы җитәкчесе (килешү буенча) |
| Мөхәррәмов Наил Мидхәт улы | Казан (Идел буе) федераль университетының Массакүләм коммуникацияләр һәм социаль фәннәр институты директоры, Гуманитар фәннәр буенча югары уку йортлары координация советы рәисе, сәясәт фәннәре докторы, профессор (килешү буенча) |
| Сафин Ленар Ринат улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Сөләйманов Рифнур Хәйдәр улы | «Татэнергосбыт» ачык акционер җәмгыяте директоры (килешү буенча) |
| Тузиков Андрей Римович | Казан милли тикшеренү технология университетының сәнәгать сәясәте һәм бизнес-административлаштыру факультеты деканы, дәүләт, муниципаль идарә һәм социология кафедрасы мөдире, социология фәннәре докторы, профессор (килешү буенча) |
| Хамаев Азат Кыям улы | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры |
| Хаҗиев Рәүзил Мәгъсүмҗан улы | «Генерацияләүче компания» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Фомин<br>Анатолий Алексеевич | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Фәйзуллин<br>Ирек Әнвәр улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры |
| Фәрдиев<br>Илшат Шәех улы | «Челтәр компаниясе» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Шаһиәхмәтов<br>Мидхәт Рәфкать улы | Татарстан Республикасы икътисад министры |
| Шәйхетдинов<br>Роман Александрович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры |
| Шакиров<br>Минсәгыйть Закир улы | Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы рәисе (килешү буенча) |

___________